**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2016 – 2018 елларда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик (иң зур) индексларын раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнарның коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмнәрен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Кушымта итеп бирелүче 2016 – 2018 елларда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик (иң зур) индексларын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

3. Әлеге Указ 2015 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 11 сентябрь
№ ПУ-854

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның « 11 » сентябрендәге
ПУ- 854 номерлы Указы белән
расланды

**2016 – 2018 елларда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик (иң зур) индекслары**

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик (иң зур) индекслары ($ИКУ^{мо}_{макс}$) 2016 – 2018 еллар чорына һәр елга түбәндәге формула рәвешендә билгеләнә:

$$ИКУ^{мо}_{макс} = \frac{\max КУ^{мо}_{регj}}{КУ^{мо}_{декабрь}} \times 100\% - 100\%,$$

монда:

$КУ^{мо}_{регj}$ – граждан тарафыннан озак сроклы чор елының граждан тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме Россия Федерациясе субъекты буенча иң югары (сум) булган j аена кулланучылар өчен иң файдасыз (коммуналь хезмәтләр өчен түләү арту күзлегеннән чыгып караганда) коммуналь хезмәтләр җыелмасы (уңайлылык дәрәҗәсе) кертелгән коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме;

$КУ^{мо}_{декабрь}$ – кулланучылар өчен иң файдалы (коммуналь хезмәтләр өчен түләү арту күзлегеннән чыгып караганда) коммуналь хезмәтләр җыелмасы (уңайлылык дәрәҗәсе) кертелгән коммуналь хезмәтләр өчен граждан тарафыннан үткән календарь елының декабрендә түләү күләме (сум);

j – озак сроклы чор елындагы ай.

___________